Хәмидуллина, Р. Г. «Өч үлемне җиңәчәксең, озын-озак яшәячәксең...»/ Р. Г. Хәмидуллина // Шәһри Чаллы. – 2024. - № 68 (25 сентябрь). – Б. 4.



# «Өч үлемне җиңәчәксең, озын-озак яшәячәксең...»



*Шәһәребезнең матур бер почмагында урнашкан күпкатлы йортның подъездына үтәм. Үзем атап килгә фатирның кыңгырау төймәсенә басам. Кайчандыр шау-гөр килеп торган ике бүлмәле фатир бүгенге көндә тынычлык кичерә. Тәзкирә Хәбинур кызы Хакова-Хәбибуллина ялгызы яшәүдән курыкмый. Ходай биргән гомерне камил акыл, сәламәтлек белән яшәргә насыйп булсын, диеп догасын укый ул.*

.

**Балачак хатирәләре**

Тәзкирә Хакова-Хәбибуллина 1934 елның 1 октябрендә Башкортстан Республикасының Шаран районы Тугызкыз-Сөнбаш авылында туа. Гаилә тигез, бер-берсенең күз карашыннан аңлап яшәгән әти-әнинең мәхәббәт җимешләре булып балалары дөньяга килә. Әмма ике туганы туып озак яшәмиләр. «Ул елларда балаларны бик яшьли авыру алып китә торды», – ди Тәзкирә апа. Алар гаиләсен дә бу фаҗига читләтеп үтми.

Тәзкирә апа үзенең дә 15 яшендә чәчәк авыруы белән авырыганын яхшы хәтерли. Районнан еракта урнашкан туган авылында табиблар булмый. Ул вакытта авылларда әбиләр медицина хезмәте күрсәтә. «Менә мине дә авырудан күрше әби дәвалады. Диагнозын да куйды, кызыгызда чәчәк авыруы, чит кешене кертмәгез, диеп чыгып киткәне бүгенгедәй исемдә», – дип искә ала ул.

**Ир кочагына салалар...**

– Әнием Галимәнең язмышы яшьтән үк бик катлаулы була. Аны беренче тапкыр 13 яшендә ике хатынлы иргә өченче хатынлыкка кияүгә бирәләр. Дөньяда ачлык, юклык хөкем сөргән еллар. Гаиләләрдә 7-8-10 бала. Менә нәкъ шул ачлыктан алып калу өчен бик яшьли кыз баланы ир кочагына салалар. Әниемнең «Беренче иремнең гаиләсе ишле иде. Ул миңа бик мәрхәмәтле булды, кызына караган кебек карады. Мине кочаклап, чәчләремнән сыйпап йоклата иде. Хатын-кыз буларак кагылуны уйламады да, урыннары җәннәтнең түрләрендә булсын. Догамнан калдырмыйм мин аны» дип сөйләгәне исемдә. Ир дигән кеше үлгәннән соң аңа туган йортка кайтып озаклап торырга туры килми. Аны икенче тапкыр олы яшьтәге иргә кияүгә бирәләр.

Әни бу йортта озак яши алмый, бу ир дә үлеп китә. Ул вакытта әниемә 17 яшь тула. Аңа Хәбинур исемле егет гашыйк була. Берсен-берсе ошатып, яратып кавышалар яшьләр. «Башта апаларда тордык, аннан читәннән үреп, балчык белән сылап өй салдык», – ди иде әни.

Тәзкирә апа үскәндә өйләре инде искереп килә торган була. Ул үскәч, чорына күрә матур йорт салып керәләр. Әти кеше авыл советы рәисе булып эшли.

**«Әти үз гаиләсен фашистлар, немецлар итеп күрде»**

Тәзкирә беренче сыйныфка укырга барасы елны сугыш башлана.

– Әтине беренче көнннәрендә үк сугышка алдылар, – диде Тәзкирә апа. Ул әтисенең сугыштан кайтканын бик яхшы хәтерли. – Бу хакта сөйләү түгел, уйларга да куркыныч, – диде, күрмедер сүзсез генә уйларына батып утыргач... – Әтиебез, Бала, Хатын төшенчәләрен сугыш кырларында онытып, ә бәлки югалтып ук, холыксыз кешегә әверелеп кайтты. Әнине, без – балаларын бик рәнҗетә торган булды. Куып чыгара, бәләкәй чакта кешегә керә идек, аннан үсә-үсә оят була башлады. Кешегә кермәдек, салкын мунчага кереп утыра торган булдык. Бик еш кына шунда йоклап кайткан вакытлар да күп булды. Үз гаиләсен фашистлар, немецлар итеп күрде. Төннәрен бик еш кына «Урра. Кузгал. В атаку» дигән сүзләрне бик күп тапкырлар ишетеп, куркып уянган чаклар булды безнең. Ул соңгы елларда кыр караулчысы булып эшләде. Безгә гомер биргән кеше бит, урыны җәннәттә була гына күрсен. 64 яшендә мәрхүм булды. Әнием күп еллар туган авылда торды, олыгайгач башта абый гаиләсендә, соңрак апа үзенә алып кайтты. Мин ул елларда гаиләм белән баракта яшәдем. Әнине үземә алып килеп карау мөмкинлегем булмады. Әниебез апаларда яшәгән вакытта янына кайтып йөрдем. 72 яшендә минем кулымда үлде, - дип хатирәләрен яңартты Тәзкирә апа.

**Кулдан көрәк төшмәде...**

Тәзкирә 1942-1949 елларда туган авылында җидееллык мәктәпне тәмамлый. Аннан кырык чакрым җирдә урнашкан Зирекле авылының татар мәктәбенә сигезенче класска керү өчен имтихан бирә. Бишле ала. Аңа математика дәресләре җиңел бирелә. Мәктәптә укый башлый, интернатта яши. Бервакыт кышкы каникулларга кайткач, әнисе бик каты авырып ята торган була. Шуңа Тәзкирәгә укуны ташларга туры килә. Әнисе терелеп аякка басканнан соң, авылдагы дус кызы белән, ике елга договор төзеп, «вербовать» итеп, Свердловск шәһәренә тимер юлга эшкә җибәрәләр. Яшәү урыннары тимер юл станциясендә вагоннарда була.

– Беренче акча алуым да шушында булды, 180 сум иде ул. Рус телен белмәгәнгә күрә күп еллар икенче разряд белән эшләдем. Эшемне яратып башкардым, тырыштым, кирка – боз вата торган җайланма, көрәк кулдан төшмәде инде. Бу якларда кибетләр елларына күрә бик бай иде. Берсеннән-берсе матур кием-салым, аяк киемнәре, ниндиен телисең, алырга мөмкин иде. Хәзер дә хәтеремдә, ситса материалның бер метры 53 тәңкә иде. Ике елда ике ай эшләгәч, миңа 18 көн ял бирделәр. Әнине, туганнарымны матур итеп киендерергә теләп, төрледән-төрле бүләкләр алдым да, бик сагынып, туган якларга кайттым. Ничектер әтигә хәбәр салганмын. Кыш. Авыл район үзәгеннән 25 чакрым ераклыкта. Бүгенгедәй күз алдымда, әти ат җигеп килгән иде. Зәмһәрир суыкта ат чанасында кайтканым хәтердә.

Өстемдәге киндер ыштан, күлмәкләремне, матур киемнәр алыштырган. Аягымдагы авылдан киткән чабаталарны калдырып, пима-киез итекләр киеп кайтуым исемдә.

Санаулы көннәр тиз үтеп китте. Аннан соң тагын бер-ике ел эшләдем дә бөтенләйгә дип авылга кайттым. Ләкин анда бер-ике ай торганнан соң, төрле гайбәт, тәмсез сүзләрдән туеп, авылдан чыгып киттем. Үзбәкстанга барып урнаштым, 24 яшемдә кияүгә чыктым. Ләкин шәхси тормышым мактанырлык булмады. Ирем туган авылымнан ун чакрымда урнашкан күрше авыл егете иде. Өйләнештек әти-әни матур итеп туй ясадылар. Төзелештә маляр булып эшләдем, нинди генә эшне кушсалар да, бик яхшы башкара идем. Ул майлы буяу белән эш итүләре үзенә бер рәхәтлек өсти иде. Аннан бер-бер артлы ике ул таптым, алар белән горурланам.

Гомерлеккә диеп сайлаган ире белән яшәп булмаячагын аңлый ике балалы ханым. Балаларын алып, күзе кая карый, шул якларга чыгып китә...

**«Ненадёжный»**

– Приютовага абыем янына 10, 7 яшьлек малайларым белән килдем. Төзелештә эшләдем, аннан бригадир итеп куйдылар, әле партиягә дә кердем. Укырга теләгем төзүчеләр техникумына алып килде. Кичке якта йөреп, укуымны тәмамладым, бик күп еллар хисапчы булып эшләдем. Берничә ел заседатель итеп судларда да утырдым әле, – дип, ялкынланып сөйләде ул.

Тәзкирә апа 54 яшемдә 90 сум акча, 2нче группа «инвалид» язуы белән пенсиягә чыга. 2нче группа инвалид эшкә урнаша алмый. Эшли дә алмый – тәҗрибәсез яшь табиб  операция вакытында хата ясаган булып чыга...

– Сигез ай шифаханәдә яттым, алмаш-тилмәш ике улым минем янга килеп йөрделәр. Карадылар, бер дә ялгызымны калдырмадылар, улларымны күрү яшәргә булган теләгемне тагын да арттырды.

Сигез ай буена система куеп, Тәзкирә апаның бавырын чистарталар, әшәке суы трубка белән махсус әзерләнгән табакка агып ята.

– Аннан начар ис килгәнне белсәгез. Түздем, уңга да сулга да селкенергә ярамый. Бераз гына селкенсәң дә, кайнар канның агып китүен сизә идем. Аның авыртуларын белсәгез, аңлатып бирү мөмкин түгел, – диеп башларын селкеп куйды. Тагын истәлекләренә үрелеп сөйләп китте: – Атнага бер табиблар бүлмәдән бүлмәгә йөреп «обход» ясыйлар, бервакыт сизәм, минем караватны читләтеп уза башладылар. Бер-берсенә каранып: «Ненадёжный...», – диләр. Ул вакытта бераз гына русча сукалый башлаган идем инде. Аңлыйм мин боларның сүзләрен. Чираттагы бер обходта минем янга тезелделәр, берсе корсагымны ачып карый, икенчесе диагнозымны укый, өченчеләреннән тагын да шул «ненадёжный» сүзе ишетелә.

Шулвакыт, үзе дә аңламаган бер көч белән мендәрдән башын күтәреп, шартлатып әйтеп куя: «Кто ненадёжный, это я ненадёжный? Нет, я надёжный, я вам еще покажу, я еще буду бегать. У меня два сына, кто их будет женить, я должна их женить, – диеп тә өсти. Сигез ай ятып, шифаханәдән чыгып киткәндә, табиб аның яныма килеп, «Женщина, вы сами себя, спасли, Вы молодцы» диеп, иңнәреннән сөеп озатып кала.

**«До глубокой старости будешь жить...»**

Тәзкирә апа бик еш кына яшь вакытында бер сукыр бабайның әйткән сүзләрен исенә төшерә. Аның Приютова дигән нефтчеләр бистәсендә эшләгән еллары була. Миңа ул: «Өч үлемне җиңәчәксең, потом до глубокой старости будешь жить», – дигән иде. Киләчәктә булачак ирем турында да әйтте. Барысы да дөрес булып килеп тора әлегә кадәр. Ә глубокий старость кайчан була икән ул, диеп көлемсерәп, шаяртып та куйды.

## 63 яшьтә шигырь яза башлый

Тәзкирә Хакова 63 яшь тулгач балалар һәм өлкәннәр өчен шигырьләр, фантастик һәм шаян-көлкеле хикәяләр, скетчлар яза башлый. Аның беренче шигырь, хикәяләр җыентыгы «Ана йөрәге» дигән исем белән 2003 елда дөнья күрә. Аннан 2009 елда «Язмыш дәрьясында» җыентыгы басылып чыга. Бүгенге көндә ул – өч китап авторы. 1994 елдан Яр Чаллы Язучылар оешмасы каршында эшләп килүче «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә йөри.

## «Подъездны бизисем килде»

...Мин, саубуллашып, подъездга чыктым. Подъезддагы сурәтләргә карыйм. «Бу кем эшләре?» дип кызыксынуыма мине озатып чыккан Тәзкирә апа, тыйнак кына итеп: «Минем эшләр», – диеп әйтеп куйды.

– Көн дә менеп-төшеп йөргән подъездны бизисем килде. Моннан 18 ел элек эшләнгән эшләр бу, – дип сөйләп китте. – Оныгымның китабыннан үземә охшаган сурәтне алдым да, 10-15 размерга зурайтып, кәгазьгә ясадым. Әйдә, җәяү төшәбез, – диде ул. – Рәсемнәр бит һәрбер катта бар. Мин баштарак рәсемнәрне биш ел саен яңарттым. Инде менә 8 ел яңартканым, тотынганым юк, буявы яхшы булды бугай, – диеп әйтеп куйды. – Һәрбер рәсемне яратып, күңелем кушканча эшләдем.

Тәзкирә апаның бу эшләренә сокланмый мөмкин түгел. Подъездның тугыз катына да берүзе рәсемнәр ясаган. Ул күңелендәге матур уй-фикерләрен буяу пумаласы аша өйнең диварларына күчергән. Алар, төрле әкият геройлары булып, подъездга кергән-чыккан һәркемне сәламләп, аларны елмаерга этәрә, матур гамәлләр белән яшәргә өнди кебек.

Тәзкирә Хакова-Хәбибуллина үзенең 90 яшьлек туган көнен һәрбер кылган матур гамәлләренә сөенеп каршы ала. Киләчәктә дә шулай гына була күрсен, Ходай Тәгалә биргән гомеренә рәхмәтле булып, бары тик саулыкта, бәхет, шатлыклы мизгелләр белән үткәрергә насыйп булсын.

**Роза Хәмидуллина**